# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге составына керүче Чуаш Аксуы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

10.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Лашчы авыл җирлегенең Чуаш Аксуы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – төзекләндерү, киртәләр кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (зиратка юл салу); - яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;- Чуаш Аксуы авылында торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, эшләр һәм договор буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?» өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 10 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны-140 кеше.

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 125 катнашучы кертелде.

Тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 90 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 90 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге составына керүче Чуаш Аксуы авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип таныrга.

2. «Югары Лашчы авыл җирлегенең Чуаш Аксуы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – төзекләндерү, киртәләр кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (зиратка юл салу); - яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;- Чуаш Аксуы авылында торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, эшләр һәм договор буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?» өчен тотуга Сез ризамы?» өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Чуаш Аксуы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ Г.Х.Усманова

Югары Лашчы авыл җирлеге
башлыгы ____________________ Г.Х.Усманова